**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**«Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

25.10.2024 ел №1

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Күтәмә авыл җирлеге**
**составына керүче Күтәмә авылы**
**торак пунктында гражданнар**
**җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 25 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2025 елда Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Күтәмә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 900 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Күтәмә торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Күтәмә торак пунктында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу)

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу).

**«РИЗА»** **«КАРШЫ»**

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

- сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының **382** катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **206** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан **206** кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге составына керүче Күтәмә авылы торак пунктында халык җыены **булып узган**, халык җыены нәтиҗәләре - **чын** дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2025 елда Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 900 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Күтәмә торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Күтәмә торак пунктында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу)

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу).

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге башлыгы Н.Г.Сабиров**